ГЛАВА СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

Совет ур., 7 нче йорт, Шиланга авылы,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1

14.11.2024 | с. Соболевское | №5

«Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Чулпаниха авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 13 декабренә Югары Ослан районының Соболевский авыл җирлегенең Чулпаниха авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Чулпаниха авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез риза булырсызмы:

- Чулпаниха авылында җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү

«ӘЙЕ» | «ЮК»

3. Йорт яны территориясендә гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Чулпаниха авылы, Үзәк урамы, 6А йорт 11:00 сәгатьтә.

4. Соболевский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы — О.Н.Майорова